**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

**КАРАР** — **РЕШЕНИЕ**

21.08.2024г. — №16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 30.04.2018 елда кабул ителгән 12 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.04.2024 елгы №290 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы №182 «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 30.04.2018 елгы №12 карарына (Советның 09.11.2020 №12, 18.10.2022 №16, 19.12.2022 №24 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
   1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 13 323 сум күләмендә расларга.»;
   1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы 30.04.2018 елгы №12 карарына (Советның 09.11.2020 №12, 18.10.2022 №16, 19.12.2022 №24 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

SCAN AnyScanner

– Нигезләмәнең 2.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Җирлек Башлыгына ай саен 1,0716 күләмендә акчалата бүләкләү түләнә.»;

– Нигезләмәнең 3.5.3. пункттагы «(катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

– Нигезләмәнең 3.5.4. пункттагы «18 процент» сүзен «41 процент» сүзе белән

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 01.07.2024 елга яңа штат расписаниеләрен расларга.
4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.
5. Әлеге карар 01.07.2024 елда барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә гамәлгә ашырыла.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan адреслары буенча бастырып чыгарырга.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Д.М.Гайнутдинов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының
21.08.2024 елгы №16 карарына

Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 18260 |
| Депутатлар | 13323 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 13323 |

AnyScanner